ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 130-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 130-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 483-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелә

**«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьяның 3 пунктындагы икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасының Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы, Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Татарстан Республикасының Зәй районы территориясендә төзелгән «Зеленая Долина» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары булган оешмалар транспорт чарасын исәпкә алу вакытыннан 10 ел эчендә салым салынудан азат ителәләр.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы

оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1; 2012, № 6 (I өлеш); 2014, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, №17 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус икътисадый зона резидентлары булган оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында»

2) 1 статьяның 1 өлешендә:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона, Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Татарстан Республикасының Зәй районы территориясендә төзелгән «Зеленая Долина» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары булган оешмалар өчен (алга таба – резидентлар булган оешмалар) Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын махсус икътисадый зона территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:»;

б) дүртенче абзацта «(2017 - 2020 елларда 12,5 процент)» сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацы (әлеге Закон редакциясендә) һәм «Махсус икътисадый зона резидентлары булган оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлешенең беренче абзацы (әлеге Закон редакциясендә) нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2025 елның 25 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары – резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Россия Федерациясе Салым кодексының 284 статьясындагы 1 пункты нигезендә махсус икътисадый зона оешмалары – резидентлары өчен Россия Федерациясе субъектлары законнары белән оешмалар табышының Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелергә тиешле салымына киметелгән салым ставкасы билгеләнергә мөмкин.

Россия Федерациясе Салым кодексының 356 статьясы нигезендә транспорт салымы билгеләнгәндә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән салым ташламалары, аларны куллану нигезләре һәм тәртибе каралырга мөмкин.

Күрсәтелгән нормалар нигезендә Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары – резидентлары өчен ташламалар каралган:

1) транспорт чарасын исәпкә кую вакытыннан алып 10 ел дәвамында транспорт салымы салудан азат итү («Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 3 пунктының икенче абзацы);

2) оешмалар табышының Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салымы буенча түбәнәйтелгән салым ставкасы («Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары – резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 өлеше, Алабуга МИЗ һәм «Иннополис» МИЗ резидентлары өчен).

Агымдагы елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 25 июнендәге 949 номерлы карары белән республика территориясендә өченче махсус икътисадый зона - Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә «Зеленая Долина» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы төзелде.

Махсус икътисадый зоналар оешмалары-резидентлары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның бертигез шартларын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының 24-ТРЗ номерлы һәм 5-ТРЗ номерлы

законнарында каралган гамәлдәге салым ташламаларын «Зеленая Долина» сәнәгать - җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентларына да бирү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, закон проектында 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына редакцияләү-техник төзәтмәләр кертү: закон исемен төзәтү, шулай ук актуальлеген югалткан нигезләмәне төшереп калдыру күздә тотыла.

**«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать – җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары – резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать – җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына һәм «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать – җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары – резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона (алга таба – «Зеленая Долина» МИЗ) эшләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм бюджеттан тыш фондларга өстәмә керемнәр күләменең артуы фаразлана.

2025 – 2034 еллар чорында резидентларның һәм идарәче компаниянең барлык дәрәҗәдәге бюджетларга турыдан-туры салым акчалары агымы 10 468 млн сум тәшкил итәчәк. Бюджеттан тыш фондларга керемнәр якынча 1 472 млн сум тәшкил итәчәк.

«Зеленая Долина» МИЗ потенциаль резидентларының финанс модельләре нигезендә ясалган бәяләмә буенча, закон кабул ителүгә бәйле рәвештә 2025 – 2034 елларга Татарстан Республикасы бюджетына керәп бетмәгән керемнәр 6,2 млрд сум күләмендә бәяләнә.